КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 6 декабрь г.Казань № 1115

Авыл хуҗалыгы өлкәсендә укыту-гамәли дәресләр үткәрүгә шартлар тудыру өчен югары белем бирүче дәүләт мәгариф оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Авыл хуҗалыгы өлкәсендә укыту-гамәли дәресләр үткәрүгә шартлар тудыру өчен югары белем бирүче дәүләт мәгариф оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына авыл хуҗалыгы өлкәсендә укыту-гамәли дәресләр үткәрүгә шартлар тудыру өчен тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына әлеге максатлар өчен карала торган акча исәбеннән конкурс нигезендә бирелә торган грантларның гамәлгә куючысы булырга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин